ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

2023 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Бортас авылында үзара салым кертү турында

2022 елның 16 ноябре №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Бортас авылында гражданнар җыены карар итте:

1.2023 елда Кама Тамагы муниципаль районының Бортас авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, көндезге уку формасында укучы студентлардан, I төркем инвалидлардан тыш, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш белән капланган чокырларны ямау, ташу, таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- спил, коры агачларны, куакларны кисү, территорияне чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);

- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерү:

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Красновидово авылы, Совет ур., 4;

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Бортас авылы, Үзәк ур., 3;

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Антоновка авылы, Колхоз урамы, 29а йорт, китапханә бинасы; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,

Красновидово авыл җирлеге башлыгы

Кама Тамагы муниципаль районы

Татарстан Республикасы районнары: А. А. Болтаков